РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОЗЮРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная 1А село Старые Зюри , 422091
тел.: (884360) 52-6-25 (факс)
E-mail: Szur.Tul @tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЖӨРИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп урамы, 1А, Иске Жөри авылы,422091
тел.: (884360) 52-6-25 (факс)
**E-mail: Szur.Tul @tatar.ru**

ОКПО 94318056 ОГРН 1061675010429 ИНН/КПП 1619004404/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№26**

**КАРАР**
**«25» июля 2019 г.**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге территориясендә махсус урыннар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру һәм җиһазлау өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү турында»гы 2019 елның 10 июлендәге 67/516 номерлы карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитеты,

## КАРАР БИРӘ:

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге территориясендә түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- Иске Җөри авылы Мәктәп урамы мәктәп бинасы янында мәгълүмат стенды;
- Иске Җөри авылы Үзәк урамы фельдшер-акушерлык пункты янында мәгълүмат стенды;
- Олы Тиләҗе авылы Узәк урамы клуб бинасы янында мәгълүмат стенды;

- Өремширмә авылы Югары урамы фельдшер-акушерлык пункты янында мәгълүмат стенды;

- Кара-Ширмә авылы Олы юл урамы шәхси эшмәкәр “Гильмуллин” кибете янында мәгълүмат стенды;

- Яңа Җөри авылы Узәк урамы 8 йорт янында мәгълүмат стенды;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау округына җибәрергә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Иске Җөри авылы, Мәктәп урамы, 1А йорт, Иске Җөри авыл җирлеге хакимияте бинасы адресы буенча Иске Җөри авыл җирлеге мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Р.Р.Мараков